# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
«Зирекле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
Кызыл Уракчы авыл торак пунктында
2024 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

**2023 елның 9 октябреннән** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Зирекле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кызыл Уракчы авыл торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2024 елда Алексеевск муниципаль районының «Зирекле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Кызыл Уракчы авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына срокдлы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш.

2.Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:
- җирлек эчендәге юлларны карап тоту;
- җирлек эчендәге юлларны ремонтлау;
- торак пунктларда урам утларын карап тоту;
- су челтәрләрен карап тоту;
-торак пунктны төзекләндерү;

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта Зирекле авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә рөхсәт бирергә.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен , кабул ителгән көннән 10 көн эчендә Зирекле авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә , Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәис
Алексеевск муниципаль районы
Зирекле авыл җирлеге башлыгы Зиннәтуллин А.Р.

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ ... АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
СОВЕТ ЕРЫКЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ